*Татар теле һәм әдәбияты укытучысы*
*Гыйләҗева Г.Р.*

# “Мин татарча сөйләшәм” республика күләм акция

***Дөньяда иң –иң матур ил -***
***Ул минем туган илем.***
***Дөньяда иң –иң матул тел -***
***Ул минем туган телем.***

*Безнең мәктәп берничә ел рәттән “Мин татарча сөйләшәм!” акциясендә бик теләп катнаша. Акциянең төп максаты – халыкны, бигрәк тә яшьләрне татар телендә сөйләшергә өндәү, кибетләрдә, урамда, китапханәләрдә, транспортта һәм төрле көнкүреш хезмәтләре күрсәтә торган җирләрдә татарча сөйләшүне гамәлгә кертү, татар теленең даирәсен киңәйтү. Укучыларда татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә кызыксыну уяту, талантлы яшьләрне барлау, иҗади фикер йөртү сәләтен үстерү, милли үзаң тәрбияләү.*

# Иң элек акциягә эзерлегебезне логотиблар ясаудан башладык






Халкым бер тумыш көндә дә
Тукаен онытмады:
Без — «Туган тел»дән туганнар,
Без — Тукай оныклары!



Моңлы тел ул, нурлы тел ул- Туган тел!-
Баш очында кояш булып тора гел!

# “Мин татарча сөйләшәм” республика күләм акция



***Исәнмесез,саумысыз, дип***
***Бүген сезгә эндәшәм.***
***Барыгыз да ишетегез –***
***Мин  татарча сөйләшәм.***

**“Мин татарча сөйләшәм”**
**республика күләм акция кысаларында үткәрелгән чаралар**
**“Мәрхәмәтле булыйк һәркемгә”**







**“Мин татарча сөйләшәм” акциясе Түбән Кәчи төп гомуми белем бирү мәктәбендә уку елы башыннан старт ала. Укучылар татар телендә уздырылган төрле чараларда, конференцияләрдә, ачык дәресләрдә, түгәрәк өстәлләрдә актив катнашалар**







Без татарча сөйләшәбез! Татар теле - безнең туган телебез булмаса да, без бик теләп өйрәнәбез! Үз телеңнән йөз чөерүчеләрне, ана телләреннән ваз кичүчеләрне без аңламыйбыз. Әйдәгез, туган телебезне саклыйк, яклыйк, яратыйк!





**Моңы булган халыкның теле була,**
**Теле булган халыкның милләте була,**
**Милләте булган халыкның дәүләте була,**
**Дәүләте булса, ул тарихта кала.**










*“Мин татарча сөйләшәм” акциясе кысаларында укучылар авыл урамнарына, җәмәгать урыннарына юл тоттылар. Изге сәфәребез мәктәбебез ишек төбеннән башланды.*






# Укучылар сәүдә үзәкләрендә








# Даруханәдә



# Музейда


Генеалогия
Wolf


КЛАССНЫЙ УГОЛОК
ТĂВАН ЧĔЛХЕ ЕПЛЕ ХИТРЕ
Wolf

**Без татарча сөйләшәбез,**
**Кушылыгыз сез дә безгә!**
**Татар теле - туган телне,**
**Яклыйк әле бергә - бергә**





**“Мин татарча сөйләшәм!” акциясендә Түбән Кәчи мәктәбе укытучылары, укучылары һәм авыл халкы :  сатучылар һәм сатып алучылар, үтеп баручылар, көнкүреш хезмәтен күрсәтүчеләр, һ.б. катнашты. Барлыгы-48 кеше .**
**Акцияне оештыручы: Түбән Кәчи төп гомуми белем мәктәбенең татар теле укытучысы**
**Гыйләҗева Гөлназ Рубин кызы.**
**Түбән Кәчи 2016**

# “Мин татарча сөйләшәм” республика күләм акция



## Түбән Кәчидә татарча сөйләшәләр

**Нигездә чуашлар яшәгән Түбән Кәчи авылында татар сөйләме дә еш яңгырый.**

Авыл мәктәбендә укучы балалар инде берничә ел рәттән "Мин татарча сөйләшәм!" акциясендә бик теләп катнашалар. Татарстанның икенче дәүләт теле булган татар телен укучылар дәресләрдә өйрәнү белән генә чикләнмиләр. Алар кибетләрдә, урамда, китапханәдә, төрле көнкүреш хезмәте күрсәтү урыннарында татарча сөйләшү күнекмәләрен үзләштерергә омтылалар. Түбән Кәчи урамнарында "Татарча ничә сүз беләсез?" уены оештырганнар, анда олысы да, кечесе дә бик теләп катнашкан. Бу хакта безгә мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлназ Гыйләҗева хәбәр итте. "Укучыларыбыз татар телендә уздырылган төрле чараларда, семинарларда, ачык дәресләрдә актив катнашалар. Татар телен теләп һәм тырышып өйрәнүләрен алар республика дәрәҗәсендә уздырылган конференцияләрдә дә ачып күрсәтәләр",–ди ул.

**6 апрель, 2016 ел.**

***Татарча да яхшы бел,***
***Русча да яхшы бел.***
***Икесе дә безнең өчен***
***Иң кирәкле татлы тел.***